**Л.Ф. Нуриева, Ф.С.Сэйфулина**
Казан федераль университеты, Казан

# МУЛЛА БИККОЛОВЛАР НӘСЕЛЕ: ИСЕМНӘРЕ ТАРИХ БИТЛӘРЕНДӘ

***Аннотация.*** *В статье исследуется жизнь и деятельность Касима и Ибрагима Бикуловых, вышедших из известного рода богословов Биккуловых. Касим известен как писатель, автор реалистических повестей, в также и рассказов стихотворных произведеий просветительского направления и составитель книг для чтения дла начальных школ. Ибрагим был известен как активный журналист начала XX века.*

***Abstract.*** *The article explores the life and work of Kasim and Ibrahim Bikulov, who came from a certain kind of theologians Bikkulovs. Kasim is known as a writer, author of realistic stories, as well as stories of poetic works of enlightenment and a compiler of books for reading for primary schools. Ibrahim was known as an active journalist of the early twentieth century.*

***Ключевые слова:*** *татарская литература начала XX века, Биккуловы, писатель, журналист*

***Key words:*** *Tatar literature of the early twentieth century, Bikkulov, writer, journalist*

Яңарыш чоры татар тормышында, туган җирләре – Яңа Тинчәле авылының (Сембер губернасы Буа өязе, Суыксу волосте, Яңа Тинчәле авылы – хәзерге Татарстанның Буа районы) тарихында Бикколовлар нәселе кылган изге гамәлләр, калдырган мәдәни мирас киңкырлы. XIX гасырның икенче яртысында Ш. Мәрҗани мәдрәсәсендә белем алган Җамаледдин Биколовның да, Казан мәдрәсәләренең берсендә укыган олы улы – мәгърифәтче, дин белгече, язучы Касыймның, атаклы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен тәмамлап, гомерен укытучылык эшенә багышлаган, публицист булып танылган икенче улы Ибраһимның да туган авыллары халкын, гомумән, төрле төбәкләрдә таралып яшәгән татар кавемен белем-мәгърифәтле итү юлындагы хезмәтләре бәһаләп бетергесез.

К. Бикколовның «Яңа Тинчәле вә аның тарихы» дигән тарихи хезмәтенең «Яңа Тинчәле мәсҗедләре» дигән бүлекчәсендә Биккол токымының бу тарафларга килеп, яшәп китүләре хакында бик кызыклы тарихи мәгълуматлар китерелә: «Беренче мәсҗед өчен (Тинчәле авылында) 1753 елда императрица Елизаветадан рөхсәт алынган. Тарихта һичбер җирдә рәсми мәсҗедкә рөхсәт алган ил юк, хәтта Казан да 1764 елда Екатерина заманынында гына, ягъни бездән 11 елдан соң гына, мәсҗедкә рөхсәт алган. ... 1785 елда Иске Чокалыдан мулла Яһүдә бине Бикколны (указлы) мулла итеп китергәннәр... Ул 50 еллап мулла булып, мәктәп ачып тирә-якларга имамнар хәзерләп чыгара. 1835 елның сентябрендә 85 яшендә вафат була. Кабере Тинчәленең төньяк тарафындагы зиратында». [Бикколов: Кулъязма, 1926] Яһүдә угылы Габделлатыйф хәзрәт хакында тарихы хезмәтләрдә шактый мәгълумат тупланган. Ш. Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбар...» [Мәрҗани, 1989: 283] китабының «Шәхесләр һәм истәлекле вакыйгалар» бүлегендә түбәндәгеләр язылган: «...Бабабыз мелла Габденнасыйр Ашыт авылында озак еллар зур мәдрәсә тотып, күптөрле фәннәрдән дәрес әйтеп, күпләр, көчләре бар кадәр, гыйлем һәм камиллеккә ирештеләр. Менә алар: мелла Исхак бине Сәгыйдь бине Колмөхәммәд әл-Казани, ... мелла Габделлатыйф бине Яһүдә бине Биккол әт-

Тинчәли...». Ягъни Габделлатыйф Биккол Ш.Мәрҗанинең, әлеге китабында язганча, «бик тәкъва һәм диндар, изге һәм саф, данлыклы һәм хәрәмнән саклanучы, дөнья эшләреннән ваз кичкән һәм шәригать кануннары белән генә эш итүче кеше буларак шөһрәт казанган...» бабасыннан белем алган кеше булган.

Ризаэддин Фәхреддиннең атаклы «Асар» китабында (Өченче җилд) Габделлатыйф бине Яһүдә бине Биккол әт-Тинчәле вә аның гаиләсе хакында шактый киң мәгълүматлар бирелгән: «Буа мозафәте Тинчәле авылында имам, мөдәррис вә шәех булып, 88 яшендә өч йөз өченче (1303/1886) ел рабигыль-ахирда вафат булды. Кабере ошбу авыл мазарындадыр.»

Галим Габделлатыйф хәзрәтнең атасы-анасы да заманының диндар, данлыклы гаиләләреннән чыккан булуларын бәян итә: «... атасы Яһүда бине Биккол Иске Чокалы карьясендә Оры Хәбибулла ишан иҗазәте берлә яран тәрбия итте. Анасы, Зиядә бинте мулла Сәйфелмөлек бине Мозаффар бине Мортаза әл-Чокалы булып, Мәрҗанинең җәдде лийммә (әнисе ягыннан бабасы) булган дамелла Габденнасыйр бине Сәйфелмөлек берлә бертугандыр.» [Фәхреддин, 2010: 136-137] Димәк, Р. Фәхреддин язмаларына караганда, Габделлатыйф хәзрәтнең улы Җамалетдин һәм Шиһабетдин Мәрҗани өчтән туган булып чыга. Китапта Габделлатыйф хәзрәтнең 9 баласы хакында да (5 ир баласы вә 4 кыз баласы) кыскача мәгълүмат бирә. Мәкаләсенең ахырында тарихчы-галим Р.Фәхреддин бу мәгълүматның оныгы Касыйм әфәнде Бикколдан алынун искәртә.

Җамаледдин Биккол – әлеге Габделлатыйф хәзрәтнең олы улы. Аның турында бер мәкаләсендә Ф.Бәшир руханиның үлеме мөнәсәбәте белән «Кояш» газетасының 8 декабрь (1914) санында некролог бирелүен яза һәм монда Җамалетдин Бикколов «үз заманына караганда иртәрәк дөньяга килгән куәт иясе» буларак бәяләнүен искәртеп үтә. [Бәшир, 2000: 173]

Җамалетдин Ш. Мәрҗани мәдрәсендә укый, мөгаллим буларак эшчәнлеген дә шунда башлап, дәресләр бирүе дә мәгълүм. 22 яшендә туган авылына кайта һәм бөтен гомерен шунда халыкны агартуга багышлый. Ике гасыр арасында атаклы рухани, үз заманы өчен алдынгы карашлы, укыту системасына яңалыклар кертүгә зур өлеш керткән, татар, гарәп телләреннән башка русчаны да яхшы белгән мәгърифәтче булып танылa. Үз заманында һәр татар зыялысы алдыра торган «Тәрҗеман» гәҗите Җамаледдиннәр гаиләсенә дә килгән, гаилә архивында, шулай ук, «Шура» журналының номерлары да сакланган.

Җамалетдин хәзрәтнең дә гаиләсе ишле була: 7 угыл һәм 2 кызы булуы билгеле. Яшәгән чорлары XIX гасыр ахыры – XX гасыр башына туры килгән мулла угылларының язмышлары шактый катлаулы.

Бикколов Ибраһим Җамалетдин улы (1884-1938), җәмәгать эшлеклесе, педагог [Татар энциклопедия сүзлеге, 2002: 103.], XX гасыр башында актив әдәби-публицистик эшчәнлек алып баручы журналист, укытучы, тәрҗемәче.

И. Бикколов язмышы һәм эшчәнлеге хакында беркүпме мәгълүмат XX гасыр ахырында Фатыйма Ибрагимова тарафыннан «Казан утлары» журналында [Ибраһимова, 1994: 188.] тәкъдим ителде.

Ибраһим башлангыч белемне Буа мәдрәсәсендә алганнан соң, Казанга килеп, атаклы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен тәмамлый. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә Ф.Әмирхан җитәкчелегендә әдәбият түгәрәге әгъзалары арасында И. Бикколов исеме дә телгә алына. Шулай ук, Казанда татар шәкертләре тарафыннан оештырылган «Ислахчылар» хәрәкәтендә (1905-1906) актив катнашучылар буларак та Ф. Әмирхан, И. Бикколов исемнәре янәшә язылган. Б. Әхтәмов җитәкчелегендә социал-демократлар партиясенең татар группасы оешу турында мәгълүматларда да бу ике исемнең янәшә булуы,

И. Бикколовның Ф. Әмирхан белән шактый тыгыз, дустанә мөнәсәбәтләрдә булуын дәлилли. «Фатих Әмирхан турында истәлекләр» китабының «Халык хәтерендә» дип аталган төзүчеләр тарафыннан тәкъдим ителгән кереш сүзендә Ибраһим Бикколовның шәхесен ачуда гаять әһәмиятле булган түбәндәге сүзләр язылган: «Сүз уңаенда И. Бикколовның Ф. Әмирханны аеруча якын күрүен әйтергә кирәк. Әдип үлем түшәгендә ятканда ул гел аның янында була, вафатыннан соң җирләү эшендә башлап йөри, калган кулъязмаларын җыештырып, тәртипкә салып куя». [Фатих Әмирхан турында истәлекләр, 2005: 13-19]. Әлеге истәлекләр китабына И. Бикколовның «Бөек язучы Фатих Зариф угылы Әмирхан» һәм «Мәрхүмнең авыруы» дип аталган ике мәкаләсе кертелгән. Мәкаләләрнең беренчесе бу китапка кыскартылып тәкъдим ителүенә карамастан, шактый зур һәм тирән эчтәлекле, яшьлек дусты – Ф. Әмирханның иҗтимагый эшчәнлегенә, аның дөньяга карашларының формалашуында, язучы булып җитлегүендә әһәмиятле урын тоткан мәдрәсә чорына, иҗатына шактый җитди бәя бирә. Авторның икенче мәкаләсе («Мәрхүмнең авыруы») язучының соңгы көннәре хакында бәян итә. Мәкаләне язучының, чыннан да, Ф. Әмирханның бу дөньядагы соңгы минутларына кадәр янында булуын раслый. Шушы китаптагы «Хәбәрче» имзасы белән язылган мәкаләдә мәрхүмне озату мәрасимендә классик язучының тәрҗемәи хәле турында чыгыш ясаучы да дусты Ибраһим Бикколов булуы хакында мәгълүмат бирелә. Бу фактлар Бикколовлар гаиләсенең татар мәдәнияты һәм әдәбияты тарихында җуелмас эз калдыруы хакында тагын бер өстәмә дәлил булып, китапка салынган төп фикерне тагын бер кат расларга мөмкинлек бирә.

Русиянең төрле төбәкләрендә яшәгән татарларга милли белем тарату уе белән янып яшәгән бер төркем яшьләр арасында «Мөхәммәдия»не тәмамлаган И. Биккулов та була, ул ерак Себер шәһәрләренең берсе – Томскига мөгаллим булып китә (1906-1913), аның журналистлык эшчәнлеге дә шушы елларда башлана. Аның үз чорының актуаль мәсьәләләрен күтәргән мәкаләләре «Шура», «Мәктәп», «Аң», «Ак юл», «Сөембикә» журналларында дөнья күрә, журналист буларак И. Бикколов «әл-Ислах», «Сибирия», «Йолдыз», «Ил» кебек гәзитәләр белән хезмәттәшлек итә. Ф.Әмирхан белән берлектә «Кояш» гәзитенең төп хезмәткәре булуы да мәгълүм.

1917 елның сентябрендә И. Бикколов Сембер шәһәрендә «Җөмһүрият» атналык газета чыгаруы, Сембер губернасы вәкиле булып Уфада үткән «Милләт мәҗлесе» эшендә катнашуы, «Милләт мәҗлесе»нең «Хокук комиссиясе» әгъзасы итеп сайлануы да билгеле.

И. Бикколовның соңгы еллары хакында мәгълүмат Үзәк Дәүләт архивында саклана. 1930-1931 елларда контрреволюцион милли оешмада катнашуда гаепләнеп кулга алынучылар арасында И. Бикколов та була. Җавапка тартылган һәм хөкем ителгәннәр исемлегендә Ибраһим Бикколов беренче булып тора. Исемлекне Җамал Вәлиди, Гали Рәхим, Садри Вәлиди-Җәләл, Шиһап Әхмәров, И. Аитов, А. Шәехгали һ.б. лар дәвам итә. 1932 елның 11 маенда алда аталган исемлектәге бик күпләр кебек И. Биккулов «Эше» буенча да карар кабул ителә: ул « гаепле » дип табыла һәм 5 елга концлагерьга хөкем ителә. Р. Мостафин язганча, «... монда шуны искәртеп үтергә кирәк: соңрак, 1937-1938 елгы «олуг террор» вакытында «солтангалиевчелек»тә гаепләнгән бу кешеләрнең һәммәсе диярлек , шул ук «җинаятьләре» өчен кабат җавапка тартылып, НКВД «өчлек»ләре («тройка») карары белән атарга хөкем ителәләр». [Мостафин, 2009: 5] И.Бикколовның язмышы да шундый булырга мөмкин.

Гомерен үз халкына тугрылыклы хезмәт итүгә багышлаган, үзенең эшен дәвам иттерүче угыллар тәрбияләгән, оныкларының да милләтне агарту эшенә хезмәт итәчәгенә иманы камил булган атаклы Габделлатыйф хәзрәтнең оныгы – классик

әдәбиятка нигез салучы Ф.Әмирханнар буынының талантлы вәкиле, ялкынлы публицист Ибраһим Бикколовның, аяныч ки, кабере дә билгеле түгел.

Касыймның тагын ике энесе – Хәмид (1883-1979) һәм Әхмәт (1899-1988) Бикколовлар хакында кыска гына мәгълүматны Якуб Чанышев язмаларында табырга мөмкин. Генерал-лейтенант Я. Чанышевның «Вспоминая былые годы» [Чанышев, 1973: 22; 37] китабында Урта Азиядә басмачылар белән көрәш алып баручы Татар бригадасы хакында язганда, халык белән аңлату эшләре алып баруда оста ораторлар буларак танылган сугышчылар арасында абыйлы-энеле Бикколовлар исеме дә телгә алына. Җамалетдин хәзрәтнең бу уллары озын, катлаулы гомер юлы узалар. Абыйлары кулга алынгач, Урта Азия якларына чыгып китергә мәҗбүр булалар, бөтен гомерләрен шунда, туган якларыннан читтә үткәрәләр. Җамали хәзрәтнең бу улларының каберләре дә шунда кала.

Бикколовлар токымы турында сүз алып барганда Касим Бикколов тарафыннан нәшер ителгән уку китапларында икенче төзүче-автор буларак Г. Госмани дип күрсәтелгән шәхес исемен дә телгә алырга кирәк. Г. Госмани (Гаяз Усманов) Касыйм Бикколовның икедән туганы (ягъни Касыймның әтисе Җамаледдин хәзрәт белән, Гаязның әнисе бертуган). Бу ике туганның эшчәнлеге нәтиҗәсендә XX гасыр мәктәп-мәдрәсәләренең аерым сыйныфлары өчен әдәби уку китаплары, табигать белеме буенча китаплар төзеп бастырылган.

XXI башында дөнья күргән «Яңа Тинчәле таңы» китабында архив документларына сылтама белән, «1896 елда авылда 1 мәктәп, 3 мәдрәсә эшли, аларда 90 бала (малайлар һәм кызлар)» укуы хакында языла һәм «XIX гасыр башында (ахырында кирәк, хата җибәрелгән) Гаяз хәзрәтнең сабак бирүе мәгълүм» [Хәлиуллин: 2006: 50] дигән сүзләр язылган. Алга таба «1910-1914 елларда Яңа Тинчәле мәдрәсәсе күтәрелеш кичерә. Биредә бу чорда Шакир хәзрәт Бакиров, Касыйм Бикколов ... Гаязетдин Усманов (Гаяз хәзрәт) мөгаллимлек итәләр» - дигән фикер дә өстәлгән.

Мулла Бикколлар династиясен дәвам иттерүче соңгы рухани, Җамалетдин мулланың улы – аянычлы язмышлы мәгърифәтче-язучы, укытучы, уку китаплары авторы Касыйм Бикколов. Кайбер чыганакларда Касыймның әтисе мәдрәсәсендә башлангыч белем алып, 1890 еллар башында хәзерге Казакъстандагы Кече Җүз Олысында мәдрәсәдә укытуы, соңрак Әстерхан якларында мәгърифәт-мәдәният эшләре белән шөгыльләнүе хакында мәгълүматлар бар. [Әхмәтҗанов, 2010: 96-100]

Төрле чыганакларга караганда К. Бикколов «ике дистәгә якын» (Ф. Бәшир), «1918 елга кадәр татар телендә 27 китап» (Р. Әхмәт), «22 китап һәм 5 мәкалә» (М. Әхмәтҗанов) бастырып чыгаруга ирешкән. Шулар арасында мәктәп-мәдрәсәләрнең аерым сыйныфлары өчен уку китаплары, дин, халык тарихы, балаларга белем, тәрбия бирү мәсьәләләренә багышланган китаплар, шигырьләр, проза әсәрләре, публицистик әсәрләр бар.

Бу чорда яшәп, исемнәрен тарих битләренә җуелмаслык итеп язып калдырган шәхесләрнең күбесенә хас булганча, Касыйм Бикколовның да эшчәнлеге күпкырлы. Авыл мулласы, мәгърифәтче-мөгаллим буларак аны балаларны укыту, тәрбияләү эшенең торышы, эчтәлеге кызыксындарган булуы һичшиксез. Әдипнең гасыр башында ук аерым сыйныфлар өчен уку китаплары чыгару белән шөгыльләнүе шул хакта сөйли. Болардан тыш К. Бикколовның дин, милләт, халык тарихына караган игътибарга лаеклы хезмәтләре бар. Туган авылының килеп чыгышына багышланган «Яңа Тинчәле вә аның тарихы» шушы юнәлештәге хезмәтләренең гүзәл үрнәге. Бу хезмәт хакында Р.А.Шәйхиев «Татарская народно-краеведческая литература XIX-XX вв.» китабында югары бәя бирә һәм «...бу төбәкне өйрәнүгә багышланган хезмәт авыл халкы арасында

грамоталылык һәм белем дәрәҗәсен өйрәнү бенча чыганак була ала. Монда тагын Яңа Тинчәле мәдрәсәсенең беренчеләрдән берсе икәнен һәм беркүпме вакыт Буа округындагы авылларда белем бирү үзәге булуы хакында да искә алмыйча булмый.» [Шайхиев, 1990: 90]

Габделлатыйф хәзрәтнең бу оныгының язмышы да зур сынаулардан тора. 1930 елда Ибраһим Бикколов кулга алынуы белән башланган куркыныч еллар зыялы, белемле мулла Бикколлар династиясенең өзелүе һәм, гомумән, тар-мар ителүе белән тәгәлләнә. Әтисе Җамалетдиннең эшен дәвам итеп, үз авылы халкын гына түгел, тирә-юньдәгеләргә дә белем бирү юлында күп хезмәт куйган, игенчелек белән шөгыльләнеп, үз көнен үзе күргән Касыйм Бикколов та репрессия еллары корбаны.

## ӘДӘБИЯТ:


1. Бикколов К. Яңа Тинчәле вә аның тарихы. Кулъязма (1926). Казан ун-тының Н.И. Лобачевский исем. фәнни китапханәсендә саклана.
2. Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1989. - Б. 283.
3. Фәхреддин Р. Асар. – Казан: «Рухият» нәшр., 2010 3-4Т. 646 б. Б. 136-137.
4. Бәшир Ф. Онытылган әдип Касыйм Биккол // Казан утлары. – 2000. – №3. – Б. 173.
5. Татар энциклопедия сүзлеге.- Казан: Татар энциклопедиясе институты, 2002. – Б. 103.
6. Ибраһимова Ф. Тарих сәхифәләрендә – татар шәхесләре. Ибраһим Биккулов // Казан утлары. – 1994. – №6. – Б. 188.
7. Фатих Әмирхан турында истәлекләр / төз. Ф. Ибраһимова, Р. Әмирхан (тулыланд. икенче басма). - Казан: Татар.кит.нәшр., 2005. – Б. 13-19.
8. Мостафин Р. Репрессияләнгән татар әдипләре. Казан: Татар.кит.нәшр., 2009. – Б.5.
9. Чанышев Я.Д. Вспоминая былые годы. – Казань: Тат.книгоиздат., 1973. – С. 22; 37.
10. Хәлиуллин И. Яңа Тинчәле таңы. – Казан: Идел-Пресс, 2006. – Б. 50.
11. Әхмәтҗанов М. Шагыйрьнең биографиясе // Мулла Касыйм Бикколов. Үткән гасыр кайтавазы... – М.: Интер-Весы, 2010. 140 с. Б. 96-100.
12. Әхмәт Р. Үткән гасыр кайтавазы // Мирас. – 2001. – № 5. – Б.44-48.
13. Шайхиев Р.А. Татарская народно-краеведческая литература XIX-XX вв. – Казань: Изд.-во Казан. ун-та, 1990. – С. 90.